БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» 05 2026 ел № 189

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «2026 елда Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру турында» 2025 елның 11 декабрендәге 338 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, 2026 елда Балтач муниципаль районы территориясендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру һәм сәламәтләндерү өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карары нигезендә (2025 елның 23 июленә булган үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач район башкарма комитетының «2026 елда Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру турында» 2025 елның 11 декабрендәге 338 номерлы карарына, 11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

- медицина пунктын эшләтер өчен рөхсәт документациясен (лицензия) рәсмиләштерү эшен оештырырга;

- «Романтик» балаларның җәйге сәламәтләндерү лагерендагы һәр сменага медицина кадрларын (фельдшердан түбән булмаган) җибәрүдә ярдәм күрсәтергә.

2. Балтач район башкарма комитетының «2026 елда Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру турында» 2025 елның 11 декабрендәге 338 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. 5.1. пунктында:

- «балаларның һәм яшьләрнең ялы өчен ата-аналар түләвенең минималь күләме» сүзләреннән соң «Романтик» балалар җәйге сәламәтләндерү лагереннан тыш» сүзләрен өстәргә;

- «Романтик» балалар җәйге сәламәтләндерү лагеренда профильле сменаларда ата-аналар түләве күләмен 25 процент күләмендә билгеләргә» дигән абзац өстәргә.

2.2. 11.4 пунктны «профильле сменаларда һәм тематик юнәлештәге сменаларда катнашуның законлылыгын раслый торган казанышлар» сүзләре белән тулыландырырга.

2.3. 15.7 пунктны «профильле сменаларда һәм тематик юнәлештәге сменаларда катнашуның законлылыгын раслый торган казанышлар» сүзләре белән тулыландырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов